РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

09.11.2015 | №1382-п

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы бюджет даирәсе
хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү
буенча Бердәм тариф коэффициентларын
һәм тариф ставкаларын (окладларын)
раслау турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты «Хезмәтләре Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелмәгән түбәндәгеләрне билгеләргә:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары);

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре , 2 нче кушымта нигезендә исәпләнә торган компенсация түләүләре күләмнәре.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә «Хезмәткә түләүнең тармак системаларын гамәлгә кертүгә, күрсәтелә торган бюджет хезмәтләренең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 22 октябрендәге 584 номерлы карарының 3 пункты нигезендә 771 сум күләмендә шәхсиләштерелгән адаптация түләүләре бирелә;

– әлеге карарның 1,2 пунктларында каралган чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф коэффициентларын һәм тариф ставкаларын (окладларын) раслау турында» 2014 елның 03 декабрендәге 1340-п номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2015 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Җитәкче Р.М. Гасимов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының 2015
елның 09 ноябрендәге 1382-п
карарына 1 номерлы
кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)**

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 2239 |
| 2 | 1,047 | 2344 |
| 3 | 1,09 | 2440 |
| 4 | 1,142 | 2557 |
| 5 | 1,268 | 2839 |
| 6 | 1,407 | 3150 |
| 7 | 1,546 | 3461 |
| 8 | 1,699 | 3804 |
| 9 | 1,866 | 4177 |
| 10 | 2,048 | 4585 |
| 11 | 2,241 | 5018 |
| 12 | 2,423 | 5426 |
| 13 | 2,617 | 5860 |
| 14 | 2,813 | 6298 |
| 15 | 3,035 | 6796 |
| 16 | 3,260 | 7299 |
| 17 | 3,511 | 7862 |
| 18 | 4,499 | 10074 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядлы түбәнрәк билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының 2015
елның 09 ноябрендәге 1382-п
карарына 2 номерлы
кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган компенсация түләүләре күләме**

| Бердәм тариф челтәренең хезмәт хакы | Компенсация түләүләре, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 1803 |
| 2 | 1703 |
| 3 | 1613 |
| 4 | 1502 |
| 5 | 1225 |
| 6 | 1200 |
| 7 | 1124 |
| 8 | 1112 |
| 9 | 1112 |
| 10 | 1100 |
| 11 | 1093 |
| 12 | 1093 |
| 13 | 1093 |
| 14 | 1093 |
| 15 | 1093 |
| 16 | 1093 |
| 17 | 1093 |
| 18 | 1093 |